ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **09.06.2023** 825 КАРАР

2023 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак йорт милекчеләре өчен торак бинаны тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексы күләмен раслау хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү буенча, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында, шулай ук мондый түләүнең иң чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча методик тәкъдимнәр раслау турында» 2018 елның 4 июнендәге 213/пр номерлы боерыгы, «Россия Федерациясе җирле үзидарәсен оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр Алабуга муниципаль районында күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чикле (максималь) индексын 5 процент күләмендә расларга.
2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм үзенең гамәлен 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 00FBD291B1574C09AAA1CBD7F6C923D025
Владелец: Исланов Роман Леонидович
Действителен с 14.03.2023 до 06.06.2024

Р.Л. Исланов